| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 5-12/тэ

"Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 декабрендәге 5-66/тэ карары белән билгеләнгән озак вакытка исәпләнгән тарифларны 2019 елга үзгәртү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, һәм 2019-2020 елларга җылылык энергиясенә (куәтенә) озакка исәпләнгән тарифларга төзәтмәләр кертү максатыннан, 2019-2020 елларга җайга салына торган оешманың планнаштырылган тиешле тулаем керемен ачыклап, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2018 – 2020 елларга тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 14 декабрендәге 5-66/тэ номерлы карарына 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 декабрендәге 5-66/тэ номерлы карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге 5-12/тэ номерлы карары редакциясендә)

## "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2018 – 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме, тариф төре | Ел | Су | Иң көчле басымлы пар | | | | Коры һәм көчсезләндерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 алып 2,5 кг/см² кадәр | 2,5 алып 7,0 кг/см² кадәр | 7,0 алып 13,0 кг/см² кадәр | 13,0 кг/см² күбрәк | |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар бүлеп каралмаган очракта, кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 1506,28 | - | - | - | - | - |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 1533,65 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 1533,65 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 1544,69 | - | - | - | - | - |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 1544,69 | - | - | - | - | - |
| | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 1592,78 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 1777,41 | - | - | - | - | - |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 1809,71 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 1840,38 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 1853,63 | - | - | - | - | - |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 1853,63 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 1911,34 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге